# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«28» июнь 2016 ел № 6/1

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль
Районы Калмия авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында

Федераль законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыКалмия авыл җирлеге Уставының 78, 79, 80 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыКалмия авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын хупларга һәм халык тыңлауларына чыгарырга.

2. Игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыКалмия авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын, 1 нче кушымта;

- «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гражданнарның фикер алышуда катнашуы турында, 2 нче кушымта;

-халык тыңлауларын үткәрү тәртибен, 3 нче кушымта.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. 2016 елның 19 июленә карар проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча түбәндәге составта комиссия төзергә:

1. Гыйлфанов Н.Р. - комиссия рәисе

2. Харрасоы З.Г. - комиссия әгъзасы

3. Гыйләҗетдинова Н.Х. - комиссия әгъзасы.

6. Халык тыңлауларын уздыру буенча комиссия ачык тыңлаулар үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссия халык алдында тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм карауга кертергә.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны халык тыңлауларын үткәрү комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Н.Р. Гыйлфанов